| | |
|---|---|
| **СОВЕТ ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

Карар

№ 1 «07» декабря 2023 ел

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 22 апрелендәге №1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Кодекс» АИС, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы ачыклаган туры килмәүләрен бетерү белән бәйле рәвештә

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” 2019 елның 22 апрелендәге №1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чиннар бирү турындагы күрсәтмә кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

1.2. 10 бүлекнең 11 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга.

1.3. 18 статьяның 7 пунктында «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.4. 17 статьяның 5 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.5. 33 бүлекнең 3 пунктындагы 1 пунктчасына «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә.

1.6. 29 бүлегенең «Татарстан Республикасы Президенты» бүлегенең 2 п.3 пунктында «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) исемен алыштырырга.»;

1.7. 23 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу.».

1.8. 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) аларга чит ил агенты статусы алу».

1.9. 18 бүлекнең 3, 8-10, 12, 13, 14 пунктларында, 29 бүлекнең 2 өлешендәге 3 пунктындагы «Татарстан Республикасы Президенты» исемен «Татарстан Республикасы башлыгы» дип үзгәртергә.

2.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Юртау авыл җирлеге башлыгы И.Ю.Кадыров